Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423643, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы,
Монашево авылы,
Мәктәп урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2023 ел. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
Карар бирәм:

1. 2023 елның 17 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында Мәктәп һәм Яңа урамнары буенча үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 17 ноябре 17.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында Ленин урамы буенча үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2023 елның 17 ноябре 18.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында Михаил Петров, Елга аръягы урамнары буенча үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урыны итеп Монашево авылы, Ленин урамы 18 йорт адресы буенча урнашкан Монашево авыл мәдәният йортын билгеләргә.

5. Монашево авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Мәктәп урамы 1 йорттан 31 йортка кадәр, Яңа урам 1 йорттан 9 йортка кадәр
Икенче этап этап: Ленин урамы 1 йорттан 52 йортка кадәр
Өченче этап: Михаил Петров урамы 1 йорттан 19 йортка кадәр, Елга аръягы урамы 1

йорттан 9 йортка кадәр

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авылы җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Чүп савытларын сатып алу;
2. Удмурт шагыйрьләренә мемориаль такта урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Монашево авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Монашево авыл җирлеге башлыгы : Р.Ф. Иосифов